**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет Татарско-Шуганского сельского поселения Азнакаевского муниципального района

423327, Республика Татарстан, Азнакаевский муниципальный район, с.Татарский Шуган, ул. Советская, д. 41в Тел. (факс) (85592) 36-1-41 Tshug .Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге башкарма комитеты

Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы Азнакай муниципаль районы, 423327, Тел. (факс) (85592) 36-1-41 Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» сентябрь 2018 ел № 13

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар-Шуган авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Әлеге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

“2019 елда үзара салым кертүгә Татар-Шуганы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1,2 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3) күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар-Шуганы авылы, Сәйдәшев ур, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан Татар-Шуганы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында.

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Башлык: ___________________ Г.З.Мияссарова